ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 24 маенда
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 146-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 11; 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5; 2013, № 10; 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 2 өлешендә «Муниципаль районнарның административ үзәкләре булып тормаучы» сүзләреннән соң «, әлеге Законның 1 нче кушымтасы нигезендә исемлектә күрсәтелгән» сүзләрен өстәргә;

2) 2 статьяда:
а) 2 өлештә «1 нче кушымтага» сүзләрен «2 нче кушымтага» сүзләренә алмаштырырга;
б) 4 өлештә «2 нче кушымтага» сүзләрен «3 нче кушымтага» сүзләренә алмаштырырга;

3) түбәндәге эчтәлектәге яңа 1 нче кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

**Муниципаль районнарның административ үзәкләре булып тормаучы, җирле үзидарә органнарына тууны, никахлашуны, аерылышуны, атасын билгеләүне, вафат булуны дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләре бирелә торган шәһәр һәм авыл җирлекләре исемлеге**

| № п/п | Шәһәр һәм авыл җирлекләренең исеме | Муниципаль район исеме |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Тирсә авыл җирлеге | Әгерҗе муниципаль районы |
| 2 | шәһәр тибындагы Актүбә поселогы | Азнакай муниципаль районы |
| 3 | Биләр авыл җирлеге | Алексеевск муниципаль районы |
| 4 | шәһәр тибындагы Түбән Мактама поселогы | Әлмәт муниципаль районы |
| 5 | Урман-Кәләй авыл җирлеге | |
| 6 | Рус Акташы авыл җирлеге | |
| 7 | Каратун авыл җирлеге | Апас муниципаль районы |
| 8 | Яңа Кенәр авыл җирлеге | Арча муниципаль районы |
| 9 | Сеҗе авыл җирлеге | |
| 10 | Иске Кырлай авыл җирлеге | |
| 11 | Ташкичү авыл җирлеге | |
| 12 | Үрнәк авыл җирлеге | |
| 13 | Шушмабаш авыл җирлеге | |
| 14 | Норма авыл җирлеге | Балтач муниципаль районы |
| 15 | Чепья авыл җирлеге | |
| 16 | шәһәр тибындагы Карабаш поселогы | Бөгелмә муниципаль районы |
| 17 | Березовка авыл җирлеге | |
| 18 | Кече Бөгелмә авыл җирлеге | |
| 19 | Подгорный авыл җирлеге | |
| 20 | Бөреле авыл җирлеге | Биектау муниципаль районы |
| 21 | Биектау авыл җирлеге | |
| 22 | Дөбъяз авыл җирлеге | |
| 23 | Усад авыл җирлеге | |

| | | |
|---|---|---|
| 24 | Танай авыл җирлеге | Алабуга муниципаль районы |
| 25 | шәһәр тибындагы Васильево поселогы | Яшел Үзән муниципаль районы |
| 26 | шәһәр тибындагы Карамалы Тау поселогы | |
| 27 | Әйшә авыл җирлеге | |
| 28 | Большие Ключи авыл җирлеге | |
| 29 | Норлат авыл җирлеге | |
| 30 | Октябрь авыл җирлеге | |
| 31 | Осиново авыл җирлеге | |
| 32 | шәһәр тибындагы Куйбышев Затоны поселогы | Кама Тамагы муниципаль районы |
| 33 | Зур Кукмара авыл җирлеге | Кукмара муниципаль районы |
| 34 | Зур Сәрдек авыл җирлеге | |
| 35 | Манзарас авыл җирлеге | |
| 36 | Габишево авыл җирлеге | Лаеш муниципаль районы |
| 37 | Нармонка авыл җирлеге | |
| 38 | Комлы Кавал авыл җирлеге | |
| 39 | Столбище авыл җирлеге | |
| 40 | Тимәш авыл җирлеге | Лениногорск муниципаль районы |
| 41 | Красная Горка авыл җирлеге | Мамадыш муниципаль районы |
| 42 | Урманчы авыл җирлеге | |
| 43 | шәһәр тибындагы Кама Аланы поселогы | Түбән Кама муниципаль районы |
| 44 | Афанас авыл җирлеге | |
| 45 | Каенлы авыл җирлеге | |
| 46 | Богородский авыл җирлеге | Питрәч муниципаль районы |
| 47 | Кощаково авыл җирлеге | |
| 48 | Ленино-Кокушкино авыл җирлеге | |
| 49 | Шәле авыл җирлеге | |
| 50 | Шигали авыл җирлеге | |
| 51 | Шәмәрдән авыл җирлеге | Саба муниципаль районы |
| 52 | шәһәр тибындагы Җәлил поселогы | Сарман муниципаль районы |
| 53 | Әҗмәкәй авыл җирлеге | Тукай муниципаль районы |
| 54 | Бәтке авыл җирлеге | |
| 55 | Князево авыл җирлеге | |
| 56 | Круглое Поле авыл җирлеге | |
| 57 | Кече Шилнә авыл җирлеге | |
| 58 | Мәләкәс авыл җирлеге | |
| 59 | Түбән Суыксу авыл җирлеге | |
| 60 | Яңа Троицкий авыл җирлеге | |
| 61 | Чистай Выселкасы авыл җирлеге | Чистай муниципаль районы |
| 62 | Ютазы авыл җирлеге | Ютазы муниципаль районы |

»;

4) 1 нче һәм 2 нче кушымталарны 2 нче һәм 3 нче кушымталар дип санарга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 09 июнь
№ 39-ТРЗ